**ГРАЖДАННАР ЖЫЕНЫ КАРАРЫ**

**Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Ульянково авыл җирлегенең Ульянково торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

**29 ноябрь, 2021 ел** **№ 1**

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2021 елның 22 ноябренә 10 сәгатьтә, 2021 елның 24 ноябренә 10 сәгатьтә, 2021 елның 24 ноябренә 11 сәгать 30 минутта, 2021 елның 26 ноябренә 14 сәгатьтә, 2021 елның 26 ноябренә 18 сәгать 30 минутта, 2021 елның 29 ноябренә 10 сәгатьтә, этаплап булган гражданнар җыеннары нәтиҗәләре белән «Сез 2022 елда яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Ульянково авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәм даими яшәүче балигъ булган һәр яшәүчедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?" соравы буенча гражданнар җыенының беркетмәсе төзелде:

- су алу скважиналарын лицензияләү буенча әзерлек эшләре;
- җирлекнең торак пунктлары чикләрендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү: кирәкле материаллар сатып алып янгын сүндерү депосы төзү, янгын сүндерү машинасын карап тоту;
- торак пункт чикләрендә автомобиль юлларын карап тоту.

« РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 331 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны - 188, бу 56,8 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар түбәндәгечә бүленде:

"Әйе" позициясе өчен гражданнар җыенында 178 катнашучы тавыш бирде; "Юк" позициясе өчен җыенның 10 катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены хәл итте:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Ульянково авыл җирлегенең Ульянково торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен - дөрес дип танырга.

2. «Сез 2022 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Ульянково авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны һәм даими яшәүче балигъ булган һәр яшәүчедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме

- су алу скважиналарын лицензияләү буенча әзерлек эшләре;
- җирлекнең торак пунктлары чикләрендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү: кирәкле материаллар сатып алып янгын сүндерү депосы төзү, янгын сүндерү машинасын карап тоту;
- торак пункт чикләрендә автомобиль юлларын карап тоту.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Ульянково авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында һәм рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка таратырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек иткән,
Ульянково авыл җирлеге Башлыгы Ф.А.Сундурова